ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28 май, 2020 ел № 39/5

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итүче күчемсез милеккә караган муниципаль милекне арендалау килешүләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына карат төзелгән җир участогы арендалау килешүләре һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларын аренда килешүләре буенча аренда түләвенә ташлама билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия икътисадының яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә аеруча зыян күргән тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән, Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл яки югары әзерлек режимы кертелгән датага Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия икътисадының яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә аеруча зыян күргән тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы боерыгы белән расланган Россия икътисадының яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә аеруча зыян күргән тармакларында эшчәнлек

алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына 2020 елның апрель - июнь айлары өчен 2020 елда Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимын кертү турында карар кабул ителгәнчегә кадәр төзелгән Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итүче күчемсез милеккә карата муниципаль милекне арендалау килешүләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участогы арендалау килешүләре (алга таба – аренда Килешүе) буенча аренда түләвенә ташлама билгеләргә.

2. Ташлама түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

1) аренда килешүендә яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә Россия икътисадының аеруча зыян күргән тармакларында, эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен куллану максатларында муниципаль мөлкәтне арендага бирү каралган булу;

2) Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек режимы яки гадәттән тыш хәл кертелгән датага кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан Россия икътисадының яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә аеруча зыян күргән тармакларында эшчәнлек алып бару, юридик затларның Бердәм дәүләт реестры яки шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестры белешмәләре нигезендә;

3) Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек режимы яки гадәттән тыш хәл кертелгән датага аренда Килешүе буенча алдагы чор өчен аренда түләве буенча бурыч булмау.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тоту Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш һәм бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев